**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 гыйнвар № 29

г. Казань

«Һөнәри уку йортларында укучыларның республика Мәдәният йорты» дәүләт бюджет учреждениесен бетерү турында

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү системасын үзгәртеп кору һәм аның белән идарә итүне оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Һөнәри уку йортларында укучыларның республика Мәдәният йорты» дәүләт бюджет учреждениесенең (алга таба – Учреждение) гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Казан шәһәре, Техническая урамы, 29 а йорты адресы буенча урнашкан учреждениене бетерү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

14 көн эчендә:

Учреждениене бетерү комиссиясе составын расларга;

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә Учреждениене бетерү тәртибен һәм вакытын билгеләргә;

Учреждениене бетерү турында карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә теркәүче органга Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен Учреждение бетерү процессында булу турында белешмәләр тапшырырга;

30 көн эчендә бетерү комиссиясенең Учреждение мөлкәтен тапшыру буенча тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшырырга;

Учреждениене бетерү буенча законда каралган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\29.docx